**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 24 сентябрендәге 4029 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләренә муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче һәм дүртенче абзацлары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен гамәлгә кертә торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 8 декабрендәге 4290 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы “Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләренә муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 24 сентябрендәге
4029 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Башкарма комитетының
Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы
муниципаль бюджет учреждениеләренә муниципаль биремне
үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган
челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга
субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы Казан шәһәре муниципаль бюджет учреждениеләренә (алга таба – учреждениеләр) муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – максатчан субсидия, субсидия) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү кагыйдәләрен гамәлгә куя.

1.2. Максатчан субсидияләр муниципаль бюджет учреждениеләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган булган Казан шәһәре Башкарма комитеты исеменнән эш йөртүче структур бүлекчә – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (алга таба – Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты) тарафыннан бирелә. Бюджет акчаларын төп бүлүче буларак, аңа тиешле финанс елына һәм план чорына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелә.

## II. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Учреждение әлеге Тәртипкә кушымтада китерелгән форма нигезендә Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына kazankddm@mail.ru электрон почтасы аша электрон документ рәвешендә яки 420107, Казан шәһәре, Петербург урамы,

70 йорт адресы буенча язма рәвештә гариза тапшыра, аңа максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә тапшырылган документларның исемлеген теркәп бирә. Әлеге исемлек түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- субсидия суммасын исәпләүне һәм нигезләүне, шул исәптән милек (күчемсез милектән тыш) сатып алуга алдан исәпләнгән сметаны, шулай ук тәэмин итүче оешмаларның (подрядчы оешмаларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен, статистик белешмәләрне һәм (яки) башка мәгълүматны да кертеп, әлеге Тәртипнең 1.1 пункты белән билгеләнгән максатларга бюджет акчаларын бирү кирәклеген нигезләүне үз эченә алган аңлатма язуы;

- сатып алырга планлаштырыла торган милек турында мәгълүмат;

- учреждениенең әлеге Тәртипнең 2.8 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар;

- субсидия бирү максатына бәйле рәвештә башка мәгълүмат.

2.2. Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) өч эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә;

в) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә субсидия бирү турында яки бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

2.3. Учреждениегә субсидия бирүне кире кагу өчен нигезләр:

- учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 1.1 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килмәве;

- учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр бирүгә Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының бюджет исемлегендә каралган бюджет йөкләмәләре лимитларының тулысынча бүленүе.

Субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүне кире кагу сәбәбен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрелә.

Кире кагу турында хәбәрнамә учреждениегә Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына электрон документ рәвешендә кергән гаризада күрсәтелгән

электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яки Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына язма рәвештә кергән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә юллана.

Кире кагу өчен нигез булып торган җитешсезлекләр бетерелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

Учреждение тарафыннан документларның тулы җыелмасы тапшырылган һәм тапшырылган документлар әлеге Тәртипнең 1.1 пункты белән билгеләнгән максатларга туры килгән очракта, шулай ук максатчан субсидия бирүне кире кагу өчен әлеге Тәртипнең 2.3 пункты белән каралган нигезләр булмаса, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә учреждениегә субсидия бирү мөмкинлеге турындагы бәяләмә рәвешендә максатчан субсидия бирү турында карар кабул итә.

2.4. Максатчан субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

С = З1 + З2 + З3 +…+Зn, биредә:

С – муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга субсидия суммасы;

З1, З2, З3,…,Зn – субсидия күләме Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль программаны раслау турындагы карары белән билгеләнгән очраклардан тыш, әлеге Тәртипнең 2.1 пунктына ярашлы рәвештә учреждение тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә билгеләнгән, муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару белән бәйле чыгымнар.

Субсидия күләме Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына тиешле финанс елына һәм план чорына билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

2.5. Максатчан субсидия бирү максатыннан Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты белән учреждение арасында Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе тарафыннан раслана торган типлаштырылган форма нигезендә килешү (алга таба – килешү) төзелә, анда шул исәптән түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) әгәр субсидияләр тиешле программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелсә, илкүләм проект (программа), шул исәптән тиешле илкүләм проект (программа) составына керүче муниципаль проект яки муниципаль программа максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче муниципаль проект исемен күрсәтеп, субсидия бирү

максатлары;

б) субсидия бирү нәтиҗәләренең конкрет, үлчәп була торган һәм әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль проектлар, муниципаль программалар нәтиҗәләренә туры килә торган (муниципаль программаларда мондый программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре булган очракта) (әгәр субсидия мондый программаларны, проектларны гамәлгә ашыру максатыннан бирелсә) күрсәткечләре һәм, тиешле программалар, проектлар нәтиҗәләренә ирешү барышында алырга планлаштырыла торган матди һәм матди булмаган объектлар һәм (яисә) хезмәтләр өлешендәге күрсәткечләрне дә кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;

в) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

г) субсидия күләме;

д) субсидияне күчерү вакыты (графигы);

е) хисап бирү вакыты;

е) учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм вакыты;

з) килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең алдан җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта;

и) Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карары буенча килешүне вакытыннан алда берьяклы тәртиптә, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә өзү өчен нигезләр:

- учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яки ябу;

- хокукый акт һәм (яки) килешү белән билгеләнгән субсидия бирү максатларының һәм шартларының учреждение тарафыннан бозылуы;

к) учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю;

л) башка нигезләмәләр (кирәк булганда).

Максатчан субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгәннән соң, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты килешү проектын формалаштыра.

2.6. Максатчан субсидия башка максатларга субсидияләр алу һәм алардан файдалану операцияләрен исәпкә алу өчен казначылык органнарында учреждение тарафыннан ачылган шәхси счетка, субсидия бирү турында карар

кабул ителгән көннән башлап, 10 эш көне эчендә күчерелә.

2.7. Субсидия бирү нәтиҗәсе – энергия ресурслары белән тәэмин итүче оешмалар челтәрләренә технологик тоташу һәм технологик тоташу турында акт алу.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткеч – энергия ресурслары белән тәэмин итүче оешмалар челтәрләренә тоташу.

2.8. Килешү төзү яки субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айга кадәр килә торган айның 1 нче числосына учреждение түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- учреждениенең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре, учреждениене үзгәртеп оештыру яки ябу буенча чараларны гамәлгә ашыруга, аварияне (гадәттән тыш хәлләрне) булдырмау, авария (гадәттән тыш хәлләр) килеп чыкканда, аның нәтиҗәләрен бетерү һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы рәвештә гамәлгә кергән суд актлары, башкарма документлар, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы, Казан шәһәре Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очракларда бурычларны каплауга субсидия бирү очракларыннан тыш, бирелгән, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы булмаска тиеш;

- башка таләпләр (кирәк булганда).

## III. Хисап бирүгә таләпләр

3.1. Учреждение бирелгән субсидиядән файдалану турында, шул исәптән учреждение тарафыннан тотылган чыгымнар һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында килешүдә китерелгән формалар буенча әлеге Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән вакытларда Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына хисап (алга таба – хисап) тапшырырга тиеш.

3.2. Учреждение максатчан субсидия бирү елыннан соң килә торган финанс елының 15 гыйнварына кадәр Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына хисап бирә.

3.3. Бирелгән максатчан субсидиядән файдалану турында хисап бирү

формасы, тәртибе һәм вакыты, субсидия бирү максатын исәпкә алып, килешү белән билгеләнгән формалар буенча төзелә.

## IV. Субсидияләр бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны үтәмәгән өчен җаваплылык

4.1. Максатчан субсидияләрнең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган өлеше Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

4.2. Хисап елыннан соң килә торган финанс елының 15 гыйнварына кадәр Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты Казан шәһәре Башкарма комитетынең Финанс идарәсенә, килешү белән билгеләнгән вакытта кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле, максатчан субсидия акчаларының хисап елы булган финанс елында файдаланылмаган һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кайтарылырга тиешле калган өлеше турында мәгълүмат җибәрә.

4.3. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә.

Максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы учреждениеләр учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булу турында мәгълүматны, шулай ук әлеге йөкләмәләрнең (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документлар күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра.

Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкәннән соң, 10 эш көне эчендә максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчаларны максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы

финанс елында файдалану турында карар кабул итә.

4.4. Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерү, шул исәптән субсидияләр биргәндә билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла

4.5. Тикшерүләр нәтиҗәсе буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, учреждение максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, шулай ук учреждение әлеге Тәртипнең III бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаган очракта, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.6. Максатчан субсидияне яки аның бер өлешен кире кайтару турында таләп, аны алган көннән алып, 30 календарь көн эчендә учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакытта үтәлмәсә, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә.

4.7. Учреждение җитәкчесе максатчан субсидияләрдән килешү белән каралган шартларда һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланган өчен җаваплы.

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты
карамагындагы муниципаль бюджет
учреждениеләренә муниципаль биремне
үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә
кертелми торган чытәрләргә технологик
тоташуны башкару буенча чыгымнарга
субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын
билгеләү тәртибенә кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә кертелми торган челтәрләргә технологик тоташуны башкару буенча чыгымнарга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алуга гариза

Субсидия бирүнең максаты: ____________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 4 | Юридик адрес | |
| 5 | Телефон номеры | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 9 | Субсидия күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган мәгълүматлар тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында миңа әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>_______________<br>(имза) | |
| 11 | Учреждениенең Тәртипнең 2.8 пункты белән каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм Тәртип нигезендә документлар исемлеге буенча кирәкле документларны тапшырам | |

Директор ___________________________________________________
(имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү датасы: 20___ елның «___» ________________